Ике-оч дистә ел элек бу урында vләннәр юк иде әле. Һәр хужалыкта kvп санда терлек һәм кош-корт асрадылар су буе авылларында. Сыер, сарыктан башка, һичшиксез, су буенда булгачтын (vз – vзеннән анлашыла да инде) vрдәкләр, казлар vрчеттеләр.

Бу мал-туар vләнне ашадылар, шуна kvрә тирә-юньдәге барлык чокырлар, уй-базлар - барысы да чабылган була иде. Ә бvген нәрсә? Яр буенда әле мал-туары булган авыл кешеләре бергәләшеп акча салышып, “электропастух” сатып алып урнаштырганнар.
- Бу хәл бушка тvгел, - дип сойли Зур Мордпошат - Большемордовскопошатский авыл жирлеге башлыгы Раис Анвәр улы Кремчеев, - мондый зур торак пункт- та нибары 16 сыер гына калды. Аларны чиратлап, элеккеге кебек котvнен мәгънәсе юк. Шуна kvрә кешеләр фәнни-техник прогресс юлыннан киттеләр дә инде.
Раис Анвәр улы, авыл халкынын йортларындагы терлек һәм кош-корт саны турында мәгълvмат турында: “Большемордовскопошат авыл жирлегенә Новое Кадышево, Вачеевка, Лобановка, Русское Корино, Мордовское Корино, Старые Шалы, Новые Шалы һәм Мордпошаты кебек торак пунктлар керә. Сигез авылда барлыгы 545 кеше яши. Топ масса – олы яшьтәге кешеләр. Мәсәлән, житмеш биш яшь- лекләр генә дә сиксәннән артык кеше яши. Аларнын kvбесенә могезле эре терлек тоту авыр. Мокша елгасына якын яшәvче кешеләр гадәттә каз һәм vрдәк асрыйлар. Бигрәк тә Мордва һәм Рус Кориноларында, Иске Шалада яшәvчеләр kvпләп vрчетә. Ә vзәк усадьбада, сонгы мәгълvматларга караганда, 1100 баштан артык кош-корт. Ә менә ботен авыл жирлеге буенча сыерлар нибары 65кә калган. Чагыштырып карасак, 2010 елда савым сыерлары саны 126 башны тәшкил иткән, ә могезле эре терлек оч йоздән артык булган”.
Kvп кенә гражданнары хәзерге шартларда сыер асраунын отышлы булмавын әйтә, сакларга да кирәк бит әле дип уфтанулы фикерне ишеттерә житәкче. Фураж һәм печән кыйммәт, атлар да юк. “...Ельниктан 25 километр ераклыкта печән чапкан балачакны искә алам. Бәйләмнәргә бәйләп, куаклар арасыннан жыйган vләнне, киптерv очен аланга чыгара торган идек. Әнием белән әбием сыер ярдәмендә сугыш кичердек дия торган иделәр. Шуна ач-ялангач тормадык, дип сойләгәннәре исемдә”, - ди Р.А.Кремчеев.

[redacted]